Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз икенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

18 май, 2023 ел № 236

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында төп эш урыны буенча эшләүче гражданнарга җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Җир кодексы, «Татарстан Республикасы Җир кодексының 21 статьясына үзгәреш кертү турында» 2021 елның 27 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2021 елның 20 маендагы 76 номерлы карары (2022 елның 30 мартындагы 154 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында төп эш урыны буенча эшләүче гражданнарга җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.3 пунктының бишенче абзацында «җир кишәрлекләре Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә төп эш урыны буенча бирелә. Богородский, Кощак һәм Шигалеев авыл җирлекләрендә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре булмау сәбәпле, җир кишәрлекләре Питрәч авыл җирлегендә бирелә.» дигән сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов